**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Об отмене карантина, установленного на территории деревни Малые Меретяки Тюлячинского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Сабинского района Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением двух месяцев со дня последнего случая заболевания животных бешенством и выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю**:

1. Отменить карантин, установленный в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных:

а) на территории деревни Малые Меретяки Тюлячинского района Республики Татарстан;

б) на следующих отдельных территориях Сабинского района Республики Татарстан:

улица Энгельса в селе Большие Кибячи;

улица Мусы Джалиля в селе Большие Нырты.

2. Признать утратившими силу:

Указ Президента Республики Татарстан от 20 января 2015 года № УП-38 «Об установлении карантина на территории села Горшково Новошешминского района Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;

Указ Президента Республики Татарстан от 28 января 2015 года № УП-70 «Об установлении карантина на территориях некоторых населенных пунктов Республики Татарстан и на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию бешенством животных»;

Указ Президента Республики Татарстан от 18 февраля 2015 года № УП-155 «Об установлении карантина на территории деревни Малые Меретяки Тюлячинского района Республики Татарстан в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Временно исполняющий обязанности**
**Президента Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань,Кремль
21 апреля 2015 года
№ УП-402

**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Теләче районының Кече Мирәтәк авылы территориясендә һәм Саба районының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле урнаштырылган карантинны бетерү турында**

Терлекләрнең котыру белән чирләвенең соңгы очрагыннан соң ике ай узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. Терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән карантинны бетерергә:

а) Татарстан Республикасы Теләче районының Кече Мирәтәк авылы территориясендә;

б) Татарстан Республикасы Саба районының түбәндәге аерым территорияләрендә:

Олы Кибәче авылындагы Энгельс урамы;

Олы Нырты авылындагы Муса Җәлил урамы.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районының Горшково авылы территориясендә һәм Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 20 гыйнварындагы ПУ-38 номерлы Указын;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының кайбер торак пунктлары территорияләрендә һәм Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 28 гыйнварындагы ПУ-70 номерлы Указын;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Теләче районының Кече Мирәтәк авылы территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле карантин кертү турында» 2015 елның 18 февралендәге ПУ-155 номерлы Указын.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2015 ел, 21 апрель
№ ПУ-402